**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «23» июленнән № 207

«2025 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында кеше иммунодефициты вирусын (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруны профилактикалау һәм көрәшү» муниципаль программасын раслау турында

Кеше иммунодефициты вирусы китереп чыгара торган авыруны профилактикалауның һәм көрәшүнең ведомствоара системасын булдыру, наркоманияне профилактикалау өлкәсендә муниципаль һәм иҗтимагый структураларның үзара хезмәттәшлеген үстерү, халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән «2025 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруны профилактикалау һәм көрәшү» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «31» июленнән
207 номерлы карары белән
расланган

«2025 - 2028 елларга
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында
кеше иммунодефициты вирусын (ВИЧ-инфекция) китереп
чыгара торган авыруны профилактикалау һәм көрәшү»
муниципаль программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2025 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруны профилактикалау һәм көрәшү |
| Муниципаль заказчы (координатор) | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, «Яңа Чишмә үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча) |
| Программаның максаты: | Яңа Чишмә муниципаль районында ВИЧ/СПИД буенча эпидемиологик вәзгыятьне тотрыкландыруга, районның авырулар, инвалидлар һәм үлүчеләр санын киметүгә, ВИЧ/СПИД белән авыручыларның гомер озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны көчәйтү. |
| Программаның бурычлары | 1. Халыкка ВИЧ - инфекцияне профилактикалау чаралары турында мәгълүмат җиткерү.<br>2. Профилактикалауның яңа медицина технологияләрен кертү, ВИЧ инфекциясен алдан ачыклау, диагностикалау, дәвалау һәм авыруларны тернәкләндерү.<br>3. Пациентлар һәм медицина персоналы арасында эчке авырулар йоктыруны профилактикалау.<br>4. ВИЧ/СПИД белән көрәшү һәм кисәтү өлкәсендә медицина хезмәткәрләренең һөнәри квалификациясен күтәрү. |
| Программаның җаваплы башкаручылары | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>«Татмедиа» АҖ филиалы «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасы редакциясе» (килешү буенча)<br>«Яңа Чишмә РҮХ» ДАССУ (килешү буенча) |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2025 - 2028 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре | Муниципаль программаны финанслау өчен кирәкле чараларның тәкъдим ителгән күләме 135,880 мең сум тәшкил итә: |

| | |
|---|---|
| | 2025 ел - 33,970 мең сум;<br>2026 ел - 33,970 мең сум;<br>2027 ел - 33,970 мең сум;<br>2028 ел - 33,970 мең сум.<br>Программаны финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты тора. |
| Төп чаралар исемлеге | 1. ВИЧ-инфекция өчен эпидемиологик күзәтү үткәрү, халыкның ВИЧ инфекцияләргә аеруча дучар булган төркемнәрен ачыклау, өстенлекле юлларны һәм ВИЧ йоктыру факторларын билгеләү.<br>2. Медицина хезмәткәрләре тарафыннан үз хезмәт бурычларын үтәгәндә аларның ВИЧ йоктыруын профилактикалау чараларын камилләштерү.<br>3. Халыкка ВИЧ - инфекцияне профилактикалау чаралары турында мәгълүмат җиткерү. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | 1. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ВИЧ/СПИД буенча вәзгыятьне стабильләштерү - ВИЧ йоктыруны профилактикалау мәсьәләләре буенча халыкның белем дәрәҗәсен арттыру. 2. ВИЧның әнидән балага йоктыру куркынычының түбән дәрәҗәсен саклап калу (2%ка кадәр) - мәҗбүри медицина тикшерүе узарга тиешле аерым категориядәге гражданнарның (донорларның) ВИЧын иртә ачыклау.<br>3. Нәтиҗәле диспансер күзәтүе һәм үз вакытында башланган дәвалау хисабына ВИЧ-инфекциялеләрнең гомер озынлыгын арттыру. |

## Кереш

Яңа Чишмә муниципаль районында кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруны киметү буенча муниципаль программа 2025-2028 елларга 1995 елның 30 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруны кисәтү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

Программа халыкның төрле катламнары һәм зәгыйфь төркемнәре арасында ВИЧ-инфекция белән авыруны киметү максатында профилактик эшне киңәйтүне, ВИЧ/СПИД таралуны булдырмауда дәүләт хакимияте органнарының ролен һәм аның нәтиҗәләрен иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә көчәйтүне күздә тота.

## Проблеманың торышы

ВИЧ-инфекция эпидемия процессында аеруча куркыныч төркем булып ВИЧ-инфекцияне җенси юл белән йоктырган затлар тора.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, авыру күрсәткечләре беркадәр кимесә дә, ВИЧ/СПИД эпидемиясе белән көрәш үзенең актуальлеген югалтмады. ВИЧ-инфекциялеләр санының яшьләр арасында күп булуы аеруча борчу тудыра.

ВИЧ-инфекцияне җенси юл белән тапшыру очраклары саны арту сәбәпле, эпидемия процессына фертиль яшьтәге хатын-кызлар күбрәк җәлеп ителә, бу исә наркотиклар кулланучы ВИЧ-инфекцияле аналардан күп санда яңа туган балалар барлыкка килүгә һәм дәүләт карамагына калдырылган балалар саны артуга китерә.

Хәзерге вакытта ВИЧ-инфекция диагнозы 22 кешедә, шуларның 20 пациенты антиретровирус терапиясе ала. Флюорография һәм диспансер тикшерүе 17 кеше узган. Китүчеләр 4 кеше: 1 кеше үлгән һәм 3 кеше махсус хәрби операциядә катнаша.

2024 елның 1 яртыеллыгында ВИЧка 1494 кеше кан анализы тапшырган, шуларның уңай нәтиҗәсе - 3 (авыруны тапшыруның җенси юлы). Куркыныч төркеменнән ВИЧ ка 40 кеше кан тапшырган, ВИЧ йоктырган 2 йөкле хатын-кыз бала тапкан.

ВИЧ-инфекцияне профилактикалау чараларын оештыру проблемага комплекслы якын килүне исәпкә алып төрле ведомстволар тарафыннан уздырыла: муниципаль мәдәният, мәгариф, спорт, «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге, «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасы редакциясе.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ВИЧ-инфекцияне профилактикалауга зур игътибар бирелә һәм кешеләрнең ВИЧ-инфекция йоктыруын кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны беренчел профилактикалауның бөтен системасы кулланыла, атап әйткәндә:

- ВИЧ-инфекция һәм СПИД (алга таба - йоктырылган иммунодефицит синдромы) мәсьәләләре буенча район халкына мәгълүмат җиткерү;

- район халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга җәлеп итү;

- мәктәп укучылары арасыннан һәм битараф булмаган гражданнарны ВИЧ - инфекцияне профилактикалау эшчәнлегенә җәлеп итү;

- үз-үзен тормышка ашыру өчен гражданнарны иҗтимагый, иҗади мохиткә җәлеп итү.

ВИЧ-инфекцияне профилактикалау методлары, барыннан да элек, Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең үзләрен, әйләнә-тирәдәге кешеләрне ВИЧ-инфекциядән яклау буенча кирәкле белемнәрен, күнекмәләрен булдыру өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Шуңа бәйле рәвештә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау чараларын (класстан тыш сәгатьләр, мәгълүмати-агарту материаллары, акцияләр, конкурслар) үткәрү эшчәнлеген активлаштырырга кирәк.

Әмма районда ачыкланган ВИЧ-инфекциялеләр буенча хәлләр киеренке кала, халык белән профилактик эшне көчәйтергә, шулай ук тәмәке тартуны, алкоголизмны һәм җенси юл белән тапшырыла торган йогышлы авыруларны профилактикалауга көч куярга кирәк.

## Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты тора.

Программаны тормышка ашыруны еллары буенча финанслау:

2025 ел - 33,970 мең сум;

2026 ел - 33,970 мең сум;

2027 ел - 33,970 мең сум;

2028 ел - 33,970 мең сум.

Программада программа чараларын гамәлгә ашыру өчен бюджеттан тыш акчалар (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчалары) һәм республикае бюджеты акчаларын җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

## Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткече - программаның максатларына һәм бурычларына ирешү.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ВИЧ/СПИД буенча вәзгыятьне стабильләштерү рәвешендә тотрыкландыру булачак.

## Программаның төп чаралары

Халыкның зәгыйфь төркемнәре арасында: инъекция наркотикларын кулланучылар, сексуаль хезмәт күрсәтүче затлар, ВИЧ-инфекцияле һәм аларның женси партнерлары арасында ВИЧ-инфекцияне профилактикалауга юнәлдерелгән максатчан чаралар үткәрү - ел саен.

ВИЧ-инфекцияле йөкле хатын-кызларны һәм алардан туган балаларны антиретровирус терапиясе белән тәэмин итү - даими.

ВИЧ-инфекцияле аналардан туган балаларның һәм хезмәт бурычларын үтәгәндә югары инфекциягә дучар булган медицина хезмәткәрләренең медицина-социаль яклангнлыгын ныгыту - ел саен.

Медицина манипуляцияләренең куркынычсызлыгын тәэмин итү, ВИЧ-инфекцияләренең профессиональ йоктыру куркынычын киметү - даими.

Яңа Чишмә муниципаль районында кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруны стабильләштерү өлкәсендәге вәзгыятьне әлеге Программа чараларына муниципаль яктан да, дәүләт ярдәме белән дә яхшыртырга мөмкин.

Программаның төп чаралары исемлеге

| Чараларның атамасы | Башкаручылар | Үлчәү берәмлеге | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында кеше иммунодефициты вирусы китереп чыгара торган авыруның таралуын профилактикалау | | | | | | |
| 1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия утырышлары саны | Яңа Чишмә муниципаль районының СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссиясе | берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 |
| 1.2. Кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыруның таралуын профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны финанслау дәрәҗәсе Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан (буклетлар, брошюралар, белешмәлекләр ясау) | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм, мәдәният, мәгариф бүлекләре | мең сум. | 33,97 | 33,97 | 33,97 | 33,97 |
| 2. ВИЧ-инфекция йоктыруны булдырмау буенча профилактик чаралар оештыру | | | | | | |
| 2.1. Халыкны ВИЧ-инфекциягә профилактик тикшерү белән тәэмин итү | Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | процент | 26 | 26 | 26 | 26 |
| 2.2. ВИЧ-инфекцияне профилактикалау өчен җаваплы медицина хезмәткәрләре өчен уку семинарлары үткәрү | Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3. Мәгариф учреждениеләре укучыларының ВИЧ-инфекция профилактикасына кертелгән өлеше | ТР Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлекге, Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | процент | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3. Тәмәке тартуны, алкоголизмны һәм женси юл белән күчә торган йогышлы авыруларны профилактикалау чаралары комплексын гамәлгә кертү | | | | | | |
| Тәмәке тартуны, алкоголизмны һәм җенси юл белән тапшырыла торган йогышлы авыруларны профилактикалау чараларында катнашучылар саны. | ТР Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | берәмлек | 2000 | 2100 | 2200 | 2300 |
| 4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә СПИДка каршы көрәшне һәм СПИДны профилактикалауны оештыру | | | | | | |
| Тикшерү изоляторларына, приемникларга керүче затларның ВИЧ-йогышына 100% тикшерүне тәэмин итү. | Россия Эчке эшләр министрлыгыныңЯңа Чишмә районы буенча бүлеге (килешү буенча) Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | процент | 90 | 90 | 90 | 90 |
| 5. ВИЧ-инфекцияне профилактикалауның үтемле чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү системасын үстерү | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Җирле матбугатта ВИЧ – инфекцияне һәм наркоманияне иҗтимагый һәм шәхси профилактикалау мәсьәләләре буенча халык арасында мәгълүмати – аңлату эшләре алып баруны тәэмин итү. | «Яңа Чишмә хәбәрләое» газетасы редакциясе (килешү буенча), Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 |
| Халык өчен ВИЧ-инфекцияне профилактикалау чаралары (хезмәт коллективларында очрашулар, класстан тыш сәгатьләр, мәгълүмати-агарту материалларын тарату, акцияләр, күргәзмәләр) үткәрү. | ТР Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Яңа Чишмә РҮХ (килешү буенча) | берәмлек | 38 | 40 | 42 | 44 |